ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

15.06.2022

г. Казань

**КАРАР**

№ 73-1/г-2022

Татарстан Республикасы халкына сатыла торган табигый газга ваклап сату бәяләрен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы федераль закон, Федераль тарифлар хезмәтенең «Халыкка сатыла торган газга ваклап сату бәяләрен җайга салу буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2011 елның 27 октябрендәге 252-э/2 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 15 июнендәге утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы халкына сатыла торган табигый газга ваклап сату бәясен 6,25 сум/куб.м күләмендә билгеләргә (өстәмә хакка салым бәясе белән).
2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы халкына сатыла торган табигый газга ваклап сату бәяләрен билгеләү турында» 16.06.2021 № 101-2/г-2021 карарын гамәлдән чыккан дип танырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач, ләкин Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Газпром» ГАҖ һәм аның аффилир затлары тарафыннан табыла торган, алга таба халыкка сату өчен билгеләнгән газга күмәртәләп сату бәяләрен раслау турында»гы боерыгы үз көченә кергән көннән дә соңга калмыйча гамәлгә керә дип билгеләргә.

Рәис А.С.Груничев